Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципальног района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

20.04.2023

Менделеевск ш.

№251

Менделеевск муниципаль районында
җылыту сезоны тәмамлану турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 06 маендагы 354 номерлы карары белән расланган гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең 5 нче пункты, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2003 елның 24 мартындагы 115 номерлы боерыгы белән расланган җылылык энергия җайланмаларын техник эксплуатацияләү кагыйдәләренең 11.7 п. нигезендә һәм тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы +8 градус Цельсий буенча һәм аннан да югарырак булганда Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Газпром теплоэнерго Казан» ҖЧҖ, «Шифалы Су-Ижминводы» шифаханәләре һөнәр берлекләренең дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе һәм районның авыл җирлекләре башлыкларына торак йортларга җылылык бирүне 2023 елның 25 апреленнән башлап туктатырга тәкъдим итәргә.

1.1 Менделеевск муниципаль районының социаль-көнкүреш билгеләнешендәге объектларына җылылык бирүне туктатырга:

- спорт объектлары 2023 елның 25 апреленнән,

-Менделеевск муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитетының административ биналарына 2023 елның 25 апреленнән,

- "Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе” МКУ объектларына 2023 елның 2 маеннан

- "Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУ объектларына 2023 елның 2 маеннан

2. Җылылык белән тәэмин итүче һәм хезмәт күрсәтүче оешмаларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. 2023-2024 еллар җылыту чорына җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык куллану объектларын әзерләү планнарын эшләргә һәм расларга һәм күчермәләрне

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетына 2023 елның 15 маена кадәр тәкъдим итәргә.
2.2. 2023-2024 еллардагы җылыту чорына җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык куллану объектларын 2023 елның 22 маеннан әзерли башларга.
2.3. Атна саен 2023 елның 22 маеннан башлап һәр сишәмбе көнне җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык куллану объектларында әзерлек эшләре барышы турында Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетына оператив хисап бирергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:

Җитәкченең беренче урынбасары А.Ф. Искаков

Төзелеш һәм ТКХ бүлеге башлыгы П.А. Лизунов

Юридик бүлек башлыгы Е.С. Царева